**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы**

# КАРАР

№ 4

2022 елның 7 ноябре,

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлегенең Иске Ибрай торак пунктында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Аксубай муниципаль районы «Иске Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 ст. нигезендә

Карар бирәм:

1. 2022 елның 18 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Иске Ибрай авылы, Октябрь урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан 1 нче мәчеттә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлегенең Иске Ибрай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Иске Ибрай авылы, Кооператив урамы, 2 нчы йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлегенең Иске Ибрай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. ТР, Аксубай районы, Иске Ибрай авылы, Үзәк урамы, 8 нчы йорт адресы буенча урнашкан 3-нче номерлы мәчеттә 2022 елның 25 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлегенең Иске Ибрай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә.

Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, мобилизацияләнүчеләрдән һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2023 елда үзара салым кертүгә 400 сум күләмендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү буенча килешәсезме?:

**1) Җирлекнең торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- авыл юлларын вак таш җәеп ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- авыл юлларын кышын карап тоту (килешү буенча түләү).

**2) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә, халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

- сууткәргечне ремонтлау өчен насос һәм комплектлар сатып алу;

**3) Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру ( урамнарны яктыртуны да кертеп):**

- урамнарны яктырту өчен товарлар сатып алу;

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

**4) Җирлектә яшәүчеләр өчен күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру:**

- балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

**5) Ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын тәэмин итү:**

- зиратны коймалау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

**6) Каты коммуналь калдыкларны туплау эшчәнлеген оештыруда (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- контейнер мәйданчыклары төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

- контейнерлар сатып алу.

“РИЗА” “КАРШЫ"

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда игъланнар такталарында элү юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы
Совет Рәисе М. Г. Минигулов